ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» апреленнән № ____

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыру турында нигезләмәне һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру тәртибен раслау хакында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлекләрен саклау, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балансслы кайнар тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тукландыруны оештыруның һәм тәэмин итүнең норматив чыгымнарын һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар ризык белән тукландыруның уртача бәясен раслау турында» 2023 елның 04 сентябрендәге 1066 номерлы нигезендә, шулай ук белем алучыларның аерым аерым категорияләренә социаль ярдәм чараларының гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру тәртибен 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән туклandыруны оештыру турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «__» апреленнән
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру шартларын тудыру максатларында эшләнде, инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру механизмын, инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыруга бәйле чыгымнарның финансбелән тәэмин итү чыганакларын, инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыруга контроль һәм җаваплылык билгели.

1.2. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 2 статьясындагы 16 пункты нигезендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар дигәндә физик һәм (яки) психологик үсешендә психологик-медик-педагогик комиссия (алга таба - ПМПК) тарафыннан расланган һәм махсус шартлар тудырылмыйча белем алуга комачаулый торган кимчелекләре булган физик затлар аңлашыла.

1.3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми, төп гомуми яисә урта гомуми белем бирүнең җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программаларын (алга таба -җайлаштырылган уку-укыту программасы) үзләштерүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, инвалид балалар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары ике тапкыр түләүсез туклану хокукына ия.

1.4. Җайлаштырылган белем бирү программасы - сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларны укыту өчен аларның психофизик үсеш үзенчәлекләрен, индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып адаптацияләнгән

һәм кирәк булганда  әлеге затларның үсеш тайпылышларын коррекцияли һәм социаль адаптациясен тәэмин итә торган белем бирү программасы.

1.5. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай тукландыру гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләргә һәм расланган үрнәк менюга туры китереп оештырыла.

1.6. Өйдә белем алучы инвалид балаларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга бушлай туклану бирү формасы - сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны туклану белән тәэмин итү максатыннан гомуми белем бирү оешмаларына җиткерелгән Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының тиешле бюджет ассигнованиеләре булганда һәм алар чикләрендә туклану бәясенә тиң акчалата компенсация

1.7. Туклану чикләүләре белән бәйле авырулары булмаган һәм дәвалау һәм диетик туклануга мохтаҗ булмаган сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен, уртача тәүлеклек наборлар «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПиН 2.3/2.4.3590-20 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының 2020 елның 27 октябрендәге карары нигезендә кабул ителә торган  нормалардан чыгып һәм мәгариф оешмасында гамәлгә ашырыла торган менюга нигезләнеп исәпләнә. Туклануда чикләүләр белән бәйле авырулары булган һәм дәвалаучы диетик туклануга мохтаҗ сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен, конкрет нозологияне һәм укучы өчен медицина оешмасының билгеләнешләрен (рекомендацияләрен) исәпкә алып, меню төзелә.

1.8. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыны, инвалид баланы һәм махсус хәрби операциядә катнашучының баласын бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин итүдән ата-ана (законлы вәкил) язма рәвештә баш тарткан очракта, күрсәтелгән укучыга мондый туклану бирелми.

## 2. Инвалид балаларга, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү турында документлар тапшыру һәм карар кабул итү тәртибе

2.1. Инвалид балаларга, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирүне сорап, ата-ана (законлы вәкил) мәгариф оешмасына түбәндәгеләрне тапшыра:

а. сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән укучыны, инвалид баланы һәм махсус хәрби операциядә катнашучының баласын әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү турында гариза;

б. гомуми белем бирү оешмасында белем алу (җайлаштырылган белем бирү программасы буенча укыту) өчен махсус шартлар булдыруга мохтаҗ булуы турында ПМПКның (үзәк яисә территориаль) гамәлдәге бәяләмәсе;

в. гариза бирүченең шәхесен раслаучы документның күчермәсе;

г) гариза бирүченең һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучының, инвалид баланың һәм махсус хәрби операциядә катнашучының баласының СНИЛС күчермәсе.

д. махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүче ата-ананың (законлы вәкилең) хәрби комиссариаттан яки хәрби частьтән белешмә күчермәсе.

2.2. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирүгә кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән тулы булмаган документлар пакетын тапшыру нигез булып тора.

2.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү турында карар әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырылган көннән алып 10 эш көне эчендә гомуми белем бирү оешмасы боерыгы белән рәсмиләштерелә. Карарларның күчермәләре Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә тапшырыла.

2.4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыга, инвалид балага һәм махсус хәрби операциядә катнашучының баласына ике тапкыр түләүсез туклану гомуми белем бирү оешмасы боерыгы басылган көннән соң икенче уку көненнән уку елы ахырына кадәр, әмма ПМПК бәяләмәсе гамәлдә булу вакытыннан артык булмаган вакытка бирелә.

## 3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирүне оештыру

3.1. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирүне оештыру өчен гомуми белем бирү оешмасы:

3.1.1. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү тәртибе һәм шартлары турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) мәгълүмат бирүне тәэмин итә;

3.1.2. әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итә, документлар пакетын формалаштыра һәм аларны саклауны тәэмин итә;

3.1.3. укучының ике тапкыр түләүсез туклануга булган хокукын тикшерә;

3.1.4. укучыны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү (тәэмин итүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

3.1.5. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларның, инвалид балаларның, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларының, шул исәптән өйдә белем алучы балаларның исемлекләрен формалаштыра;

3.1.6. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларның, инвалид балаларның, махсус хәрби операциядә катнашучыларның

балаларының ике тапкыр түләүсез туклану бирү буенча хисап төзүне һәм гамәлгә куючыга тапшыруны тәэмин итә;

3.1.7. сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына, өйдә белем алучы балаларга ике тапкыр түләүсез туклану бирүне һәм акчалата компенсация түләүне белән тәэмин итә

## 4. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү

4.1. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү белән бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына каралган ассигнованиеләр чикләрендә һәм ел саен индексацияләнгән гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына ярашлы рәвештә башкарыла.

4.2. Муниципаль гомуми белем бирү учреждениесенә акчалар күләме әлеге категорияләргә керүче укучыларның фаразланган саныннан һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турындагы тиешле карарлар белән билгеләнгән туклану бәясеннән чыгып билгеләнә.

## 5. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучы статусына ия балаларга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирүгә контроль һәм җаваплылык

5.1. Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучыга, инвалид балаларга, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына ике тапкыр түләүсез туклану бирү өчен шәхси җаваплылык йөртә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «__» апреленнән
___ номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыру турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «Россия Федерациясе мәгариф турында» Федераль законның 29.12.2012 № 273-ФЗ номерлы законы белән;

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыру тәртибен билгели, балаларның кайнар ризык белән тукландыруны оештыруның шартларын, кагыйдәләрен һәм таләпләрен, шулай ук түләүсез тукланууга мохтаҗ укучыларның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чараларын билгели.

## 2. Укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыруда төп бурычлар

2.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыруда төп бурычлар булып тора:

- укучыларны тиешле яшь буенча физиологик матдәләргә һәм энергиягә ия булган ихтыяҗларга, рациональ һәм балансы туклану принципларына җавап биргән кайнар ризык белән тукландыру;
- ашамлыклар әзерләү өчен кулланыла торган азык-төлек продуктларының һәм кайнар ризык белән тукландыруның куркынычсызлыгы һәм гарантияләнгән сыйфаты;
- тулы канлы һәм сәламәт туклану принципларын пропагандалау;
- кайнар ризык белән туклануны оештыруга бүлеп бирелә торган акчалардан гамәлдәге законнар таләпләре нигезендә файдалану;
- белем алучыларның өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ аерым категорияләре өчен бушлай кайнар ризык белән туклануын оештыру.

## 3. Кайнар ризык белән туклануны финанслау тәртибе

3.1. Кайнар ризык белән туклануны финанслау башкарыла:

1-4 сыйныф укучыларына:

- Россия Федерациясе бюджеты чаралары исәбеннән (башлангыч гомуми белем ала торган 1-4 сыйныф укучыларын бер тапкыр бушлай туклындыруны тәэмин итүгә);

- ата-аналар түләве исәбеннән озайтылган көн төркеменә йөрүче 1-4 сыйныф укучыларына.

5-11 сыйныф укучыларына:

- Россия Федерациясе бюджеты чаралары исәбеннән (5-11 сыйныф укучыларын туклындыруны тәэмин итүгә);

- ата-аналар түләве исәбеннән;

- җирле бюджет чаралары исәбеннән, белем алучыларның өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ аерым категорияләрен бушлай кайнар ризык белән туклануын оештыруга.

3.2. Кайнар ризык белән туклындыру Россия Федерациясе бюджеты чаралары, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары, җирле бюджет чаралары, ата-аналар түләве исәбеннән, бер балага бер көнгә туклану азыгы нормасыннан чыгып, санитар-эпидемиологик кагыйдәләр нигезендә, расланган меню буенча гамәлгә ашырыла.

3.3. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ата-ана түләвен һәр айның 25 нче числосына кадәр кертәләр. Ата-аналар түләве хисап чорына азык-төлеккә бәяләргә (шул исәптән кайнар ризык белән туклындыру аукционнарның нәтиҗәләренә) бәйле.

## 4. Белем алучыларның өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ аерым категорияләре өчен бушлай кайнар ризык белән туклануын оештыру тәртибе

4.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә бушлай кайнар ризык белән туклануын оештырганда өстәмә социаль ярдәмгә алу хокукына укучыларның түбәндәге категорияләре ия:

- 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган, кеше башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан түбәнрәк булган күп балалы гаиләләрдән булган балалар;

- җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган аз керемле гаиләләрдәге балалар;

- инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән статусына ия укучылар, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балалары

4.2. Өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ аерым категория укучыларга түләүсез кайнар туклану алу өчен документлар исемлеге:

Аз керемлеләр исәбендәге 4 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләгән аз керемле күп балалы гаиләләр өчен:

- әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә документлар кушып, ата-ананың (законлы вәкиленең) берсенең язма гаризасы:

- барлык балаларга (эшләмәүчеләргә һәм гаиләдә яшәүчеләргә) туу турында таныклык күчермәләрен;

- социаль түләүләр билгеләү турында өземтә;

- бушлай кайнар ризык белән туклану бирүдә өстәмә социаль ярдәм күрсәтелүгә мохтаҗ укучыны кертү турында комиссия карары.

4.3. Белем алучыларның өстәмә социаль ярдәмгә мохтаҗ аерым категорияләре өчен бушлай кайнар ризык белән туклану бирү өчен нигез булып тора:

Күпбалалы аз керемле гаиләләр өчен:

- бушлай кайнар ризык белән туклану бирүдә өстәмә социаль ярдәм күрсәтелүгә мохтаҗ укучыны кертү турында комиссия карары.

4.4. Әлеге Нигезләмәнең 4.1. пунктында күрсәтелгән бушлай кайнар ризык белән туклану бирүгә мохтаҗ белем алучыларның аерым категорияләре өчен өстәмә социаль ярдәм чарасы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль учреждениеләренә һәр уку елына расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә ата-аналарны туклану өчен ата-аналар түләвеннән азат итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Туклануны оештыру процессында катнашучыларның бурычлары

5.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль учреждениеләрендә белем алучыларның аерым категорияләренә бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чаралары билгеләү өчен комиссияләр төзелә.

Комиссия составына гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе, укучыларның кайнар ризык белән туклануын оештыру өчен җаваплы зат вазифаи зат педагогик коллектив составыннан билгеләнгән булырга тиеш) һәм ата-аналар комитеты вәкилләре керә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким булмаска тиеш.

5.2. Комиссия белем алучыларны бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗлар дип билгеләү турында беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелгән карар (алга таба - белем алучыны бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ дип билгеләү турында комиссия карары) кабул итә.

5.2.1. Комиссия:

- сыйныф җитәкчесенә яисә мәгариф оешмасы җитәкчесенә тәкъдим ителгән ата-ана(лар)ның (законлы вәкиленең) гаризаларын карый;

- белем алучыны бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ дип билгеләү турында яисә бушлай кайнар ризык белән тукландырудан баш тарту турында карар кабул итә;

- сыйныф җитәкчесенең үтенече буенча, торак-көнкүреш шартларын тикшерү максатыннан гаиләгә килергә һәм әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә торак-көнкүреш шартларын тикшерү актын төзергә хокуклы.

- ташламалы категориягә кертелгән укучыларның исемлеге сентябрьдә 10 числога кадәр формалаштырыла.

5.2.2. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе:

- ата-аналарга (законлы вәкилләргә) бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә социаль ярдәмнең өстәмә чараларын бирү турындагы мәгълүматны җиткерә;

- гомуми белем бирү учреждениесендә кайнар ризык белән тукландыруны оештыру буенча комиссия төзү турында боерык чыгара;

- бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ белем алучыларга кайнар ризык белән туклану билгеләү турында боерык чыгара;

- ел саен 25 сентябрьгә кадәр һәм аннан соң гаризалар кергәндә һәм аларны уңай караганда боерыкларның күчермәләрен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә тапшыра;

- федераль, региональ һәм муниципаль норматив актлар, санитария кагыйдәләре һәм нормалары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә укучыларны бушлай кайнар ризык белән тукландыруны оештырган өчен җаваплылык тота;

- гомуми белем бирү учреждениесе хезмәткәрләре арасыннан укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыруга җаваплы вазыйфаи затны билгели һәм аңа вазыйфалар беркетә.

5.2.3. Сыйныф җитәкчеләре:

- ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) укучыларның аерым категорияләренә өстәмә рәвештә социаль ярдәм чаралары бирү турында язмача рәвештәге гариза кабул итәләр;

- гаризаларны алынганнан соң өч көн эчендә комиссиягә карауга җибәрәләр;

- сыйныфта укучыларның кайнар ризык белән туклану исәбен алып баралар;

- комиссия каравына бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чараларына мохтаҗ укучылар исемлегенә кертү турында гариза-үтенечнамәләр (ирекле формада бирү хокукына ияләр.

5.2.4. Ата-аналар (законлы вәкилләр):

- комиссиягә укучыларның аерым категорияләренә бушлай кайнар ризык белән тукландыру рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чаралары бирү турында гариза бирәләр;

- гаризада күрсәтелгән тапшырылган документларның дөреслеге өчен тулы җаваплылык тоталар.

2025 елның «__» апреленнән ____
номерлы Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районының
муниципаль бюджет гомуми белем бирү
учреждениеләрендә укучыларны кайнар
ризык белән туклландыруны оештыру
турында нигезләмәгә һәм Татарстан
Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районының муниципаль гомуми белем
бирү учреждениеләрендә инвалид
балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре
чикләнгән укучылар статусы булган
балаларны, махсус хәрби операциядә
катнашучыларның балаларын ике тапкыр
бушлай ике тапкыр туклландыру
тәртибенә
1 нче кушымта

___________________________________
муниципаль бюджет гомумбелем
бирү учреждениесе директорына
___________________________________
___________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме,
атасының исеме)
Адресы_____________________________
___________________________________

Гариза

Аз керемле гаилә, 4 баладан күбрәк бала тәрбияләнә торган күп балалы аз керемле гаилә әгъзасы, инвалид бала; укучы, ата-анасы (законлы вәкиле) махсус хәрби операциядә катнашучының баласы булган минем балам _________________________________ (Ф.И.О.) бушлай туклану хокукын бирүне сорыйм.

Гаризага түбәндәге документларны беркетәм:

- күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсе -___.
- барлык балаларның тууы турында таныклык күчермәләре -___.
- гамәлдәге ПМПК бәяләмәсе -___.
- паспорт күчермәсе -___.
- гариза итүченең һәм сәламәтлеге чикле укучы һәм инвалид баланың СНИЛС күчермәләре -___.
- хәрби комиссариаттан яки хәрби частьтан белешмә -___.
- билгеләнгән социаль түләүләр турында белешмә -___.

Имза
Көне

2025 елның «__» апреленнән ___
номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар ризык белән тукландыруны оештыру турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә инвалид балаларны, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусы булган балаларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын ике тапкыр бушлай ике тапкыр тукландыру тәртибенә
2 нче кушымта

___ - _____________-____ елда туган
_____ сыйныф укучысы __________________________________________________ ның
(баланың ФИО тулысынча, туу датасы)
торак-көнкүреш шартларын тикшерү
АКТЫ

20___елның ____ __________

Түбәндәге составтагы комиссия: ______________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
__________________түбәндәге адрес буенча укучының торак-көнкүреш шартларын һәм тәрбия шартларын тикшерде: ______________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

Тикшерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды:
1. Гаилә составында (ФИО):
Атасы ______________________________________________________________
Анасы ______________________________________________________________
Балалар (ФИ, туган елы)______________________________________________
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
Әлеге адрес буенча яшәүче башка гаилә әгъзалары:
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________

2. Яшәү шартлары
- Торак: хосусый, муниципаль, арендада.
- Бүлмәләр саны ___
Йортның сыйфаты: нормаль хәлдә, тузган, авария хәлендә
- Төзекләндерү: - сүүткәргеч: салкын, кайнар, су булмау; ванна; канализация; газ.

- Җылыту : үзәк, мич, башкасы (______________________________);
Башка күрсәткечләр: ____________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

3. Торакның санитар торышы: - яхшы, канәгатьләнерлек, канәгатьләнерлек түгел
- санитария-гигиена нормаларын үтиләр (үтәмиләр);
4. Укучы: - үз бүлмәсе бар (юк);
- үзенең эш урыны бар (юк);
- укучының уку өчен кирәкле шәхси әйберләре булу.
5. Ата-аналар: - баланың укуына тиешле игътибар бирәләр (бирмиләр);
- мәктәпкә йөриләр (йөрмиләр);
- уку процессын контрольдә тоталар (контрольдә тотмыйлар).
6. Гаиләдә үзара мөнәсәбәтләр: гаиләдә атмосфера - дустанә, җылы, гаилә әгъзалары арасында ышанычлы мөнәсәбәтләр;
бала ата-анасы белән читләшкән мөнәсәбәттә, үзара аңлашу юк.
7. Гаилә тәрбиясе үзенчәлекләре: ата-аналар баланың үз-үзен тотышын кырыс контрольдә тота, укытучылар белән хезмәттәшлек итә;
баланың мөстәкыйльлеген чиклиләр, укытучылар белән каршылыкларга керәләр.
8. Гаиләнең матди хәле:
- югары матди җитешле;
- урта матди җитешле (тәэмин ителгән);
- түбән матди җитешлелек (аз тәэмин ителгән);
- мохтаҗлар (хәерчелек чигендә).
- атасы эшләми;
- анасы эшләми
9. Балигъ булмаган (гаилә) нинди ярдәмгә мохтаҗ (социаль, хокукый, педагогик, психологик, матди) ______________________________________

Нәтиҗә: 1. Көнкүреш шартлары канәгатьләнерлек, яхшы, начар.
2. Гаилә әгъзалары белән үзара мөнәсәбәтләр яхшы, канәгатьләнерлек, начар.
3. Гаилә имин (гаилә имин түгел, гаилә борчу тудыра)
4.__________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Комиссия әгъзалары:
____________________________________/_________________________/____________
(Ф. И. О.) (вазифасы) (имзасы)
____________________________________/_________________________/____________
(Ф. И. О.) (вазифасы) (имзасы)
____________________________________/_________________________/____________
(Ф. И. О.) (вазифасы) (имзасы)

Акт белән таныштым ________________________________________________________
Ата-аналарның ФИО, дата, имза